МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.05.2017 № 21-95-74

Казан ш.

“Күздә тотылган администраторлар белән берлектә эшләү тәртибе турында” 09.02.2011 ел, № 21-95-11 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының норматив-хокукый актларын законга туры китерү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. “Күздә тотылган администраторлар белән берлектә эшләү тәртибе турында” 09.02.2011 ел, № 21-95-11 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Федераль казначылык тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасында керемнәрнең учетын алып бару һәм аларны Россия Федерациясе бюджет системалары бюджетлары арасында бүлү тәртибен раслау турында” 18 декабрь, 2013 ел, № 125н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган, Федераль казначылык тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасында керемнәрнең учетын алып бару һәм аларны Россия Федерациясе бюджет системалары бюджетлары арасында бүлү тәртибенең 55 пункты нигезендә”;

әлеге боерык белән расланган, түләүләрнең кемгә каравын тәгаенләү (ачыклау) өчен, Татарстан Республикасы бюджетына кабул ителә торган, ачыкланмаган керемнәргә кертелгән түләүләр администраторлары – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән берлектә эшләү тәртибенең 5 пунктында:

беренче абзацта «17 01020 02 0000 180» саннарын «1 17 01020 02 0000 180» саннарына алыштырырга;

«б» пунктчасында «100 1 17 01010 01 0000 180» саннарын «100 1 17 01010 01 6000 180» саннарына алыштырырга.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алуга җибәрергә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин